КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 октябрь г.Казань № 948

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 8 август, 565 нче карары белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 8 август, 565 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 июль, 587 нче; 2018 ел, 19 ноябрь, 1013 нче; 2019 ел, 12 июль, 568 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан А.И.Габдрәшитовны, А.Ш.Сәетованы чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Барабанова Екатерина Андреевнаны | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасарын |
| Садыйкова Рината Наил кызын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасарын; |

Р.А.Ратникова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү комиссиясе рәисе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

А.С.Кондратьев вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Премьер-министрының иҗтимагый берләшмәләр буенча киңәшчесе, комиссия секретаре (килешү буенча)»;

В.А.Власов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автострада» акционерлар җәмгыятенең директорлар советы рәисе»;

Р.Г.Садыйкова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының югары белем бирүче «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Фармэксперт» төбәк фәнни-сынау үзәге җитәкчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин